ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЕЛАБУЖСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АЛАБУГА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

28.12.2024 № 2236

Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының «Махсус хәрби операциядә катнашу максатларында Россия Федерациясе Кораллы Көчләрендә хәрби хезмәт узу турында контракт төзегән Россия Федерациясе гражданнарына бер тапкыр бирелә торган акчалата түләүне бирү Тәртибен раслау хакында» 2024 елның 27 июлендәге 935 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Аерым категория гражданнарга социаль ярдәм күрсәтү максатларында, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 20 статьясындагы 5 пунктының икенче абзацы, Алабуга муниципаль районы муниципаль берәмлеге Уставының 47 статьясы, Алабуга муниципаль районы Советының «Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставын кабул итү турында» 2020 елның 17 августындагы 491 номерлы карары нигезендә, Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты

КАБУЛ ИТТЕ:

1. Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының 2024 елның 27 июлендәге 935 номерлы карары белән расланган махсус хәрби операциядә катнашу максатларында Россия Федерациясе Кораллы Көчләрендә хәрби хезмәт узу турында контракт төзегән Россия Федерациясе гражданнарына бер тапкыр бирелә торган акчалата түләүне бирү Тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Тәртипнең 1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Контракт төзегән гражданнарга бер тапкыр бирелә торган акчалата түләү күләме:

04.03.2024 елдан 31.05.2024 елга кадәр – 300 000,0 (өч йөз мең) сум, 01.06.2024 елдан 05.08.2024 елга кадәр - 200 000,0 (ике йөз мең) сум,

06.08.2024 елдан 31.12.2024 елга кадәр-300 000,0 (өч йөз мең) сум.».

2. Әлеге карар рәсми рәвештә бастырып чыгарылырга тиеш.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көннән үз көченә керә һәм 2024 елның 4 мартыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары Н.Д. Курамшинга йөкләргә.

Җитәкче Э.Р. Әхмәдиева